Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомарбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 14**

Шомарбаш авылы 2018 елның 30 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге "Физик затлар мөлкәтенә салым турында"гы 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Салым кодексының (икенче өлеше) 32 бүлеге, 2017 елның 30 сентябрендәге "Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 286-ФЗ номерлы Федераль закон, 2018 елның 3 августындагы "Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенең 52 маддәсенә һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында" 334-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Шомарбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге "Физик затлар мөлкәтенә салым турында"гы 11 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлеге Советының 15.06.2015 № 13, 15.10.2015 № 4 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

1 пунктчада икенче абзацны ", шул исәптән әлеге пунктның 4,5 пунктчаларында күрсәтелгән салым салына торган объектларда урнашкан" сүзләре белән тулыландырырга;

2 пунктчада икенче абзацны "фатир" сүзеннән соң ",фатир өлешләренең, торак йортлар өлешләренең" сүзләре белән тулыландырырга;

3 пунктчада дүртенче абзацтагы "бер торак бина (торак йорт)" сүзләрен "бер торак йорт" сүзләренә алыштырырга.

2. Карар рәсми төстә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. 2018 елның 3 августындагы "Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенең 52 маддәсенә һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында" 334-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (әлеге карар редакциясендә) 2

пункттагы 1 пунктчаның икенче абзацы һәм 2 пунктчаның икенче абзацы нигезләмәләренең көче 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүматлар стендларында: Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы Шомарбаш авылы, Совет урамы, 47 нче йорт; Таулар авылы, Ленин урамы,50А йорты; Алан-Полян авылы, Я.Емельянов урамы,6нчы йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 нчы йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

5.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлеге Башкарма комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомарбаш авыл җирлеге
Башлыгы И.Н.Сафин